**2021 ел өчен директорның ачык отчеты.**

**Сл.1** 2021-2022 уку елына мәктәп эшчәнлегенә анализ

*Олы Нырсы урта мәктәбенең* белем бирү программасы һәм укыту планы мәктәпнең төп дәүләт функциясен үтәүгә - гомуми урта белем бирү, укыту процессы барышында бала шәхесен үстерүдә чагыла.
**Сл.2** Мәктәп тулысынча укытучы кадрлар белән тәэмин ителгән , *23 педагогик* хезмәткәр белем бирә, шуларнын 91 % квалификацион категорияле, белем йортында 7 авылдан балалар укый, 6 авылга (35 балага)транспорт белән йөрү мөмкинлеге тудырылган.
**Сл.3** 2021/2022 нчы уку елына бурычлар куйдык. Слайдка игътибар итегез.
Бу бурычларны үтәү өчен төп шарт - һәр баланың мөмкинлегеннән һәм сәләтеннән чыгып, һәр дәрестә эшчәнлеккә катнашуын оештыру.
**Сл.4** Педагогик процесс күптөрле инновацион технологияләргә, фәнни һәм гамәли идеяләргә нигезләнеп алып барыла. Грант кысаларында конкурста катнашу укытучыларга мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итә. Камиллеккә чикләр юк икәнен барыбыз да белә. Гүзэл Хамзовна –"Ел укытучысы" муниципаль этабы призеры. Мәктәпнең 6 укытучысы Грант иярәре.
**Сл.5** Бу уку елында без 3 Грант программасында катнаштык. Грантларда катнашу – яңа мөмкинлекләргә юл ача.
**Сл.6-7** Профориентация, белем-тәрбия бирүнең нәтиҗәсе мәктәпне тәмамлаган укучыларыбызда күренә. Алар үз урыннарын табып матур гына тормыш итәләр. 9 нчы, 11 нче сыйныфны тәмамлаган егет һәм кызларларыбыз, барсы да кулларына аттестат алып, югары уку йортларына, ссузларга керделәр. 4 укучы 10 нчы сыйныфка килде.
Узган 2020-2021 уку елы нәтиҗәләренә күз салсак: мәктәптә 59 укучы белем алды. Фән буенча белем стандартының мәҗбүри минимумы федераль компонентын һәр укучының үзләштерүенә ирешелде.
*Ел нәтиҗәләре буенча Өлгереш-100%, сыйфат-65%. Бу алдагы ел белән чагыштырганда югарырак күрсәткеч.*
***Сл.8-9*** *ЕГЭ нәтиҗәләрен слайдта күрә аласыз:Рейтинг уңай.*
Быелгы уку елында мәктәптә 54 (3 укучы Айдар филиалында) укучы белем ала. 9 нчы сыйныфны 8 укучы тәмамлый. Дәүләт йомгаклау аттестациясенә даими әзерләнәбез. Бу юнәлеш буенча юл картасы билгеләнде. Мониторинг нәтиҗәләре узган уку елы белән чагыштырганда уңай якка үзгәрешне күрсәтә.
**Сл.10-11** 2020-2021 уку елы безнең өчен бик уңышлы булды. Чөнки регион һәм республика күләмендә фән олимпиадаларыннан укучыларыбыз 5 призлы урын яулап районда иң яхшы мәктәп исеменә лаек булдык.
Бу уку елында мәктәп укучылары муниципаль тур олимпиадаларындагы уңышлары: 10 –җиңүче, 13- призер. 10 укучыбыз физик тәрбия, хокук белеме, рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм татар әдәбияты, биология республика һәм регион фән олимпиадаларына әзерләнә. Аларга уңышлар телибез.
**сл.12-14** 2021 ел — Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы булды. Бу ел уңаеннан мәктәп бизәлде, эш планы төзелеп, күркәм традицияләрне, гореф-гадәтләрне искә алу, аларны кабат кайтару чаралары үткәрелде: "Моннар агыла туган җирдә", "Милли ярминкә", " Шахмат зонасын ачу" шундыйлардан.

Март аенда «Җәшнә кояш, җалтыра " керәшен мәдәнияте республика фестивале үткәрелде. Фестиваль кысаларында халык иҗаты конкурсы һәм керәшеннәрнең декоратив-гамәли мәдәният эшләнмәләре, көнкүреше, гореф-гадәтләре күргәзмәсе үткәрелде. Фестивальдә республиканың 4 районыннан фольклор коллективлар катнашты. Махсус кунаклар: Татарстан республикасы керәшен җәмгыяте җитәкчеләре, күренекле артистлар, "Туганайлар" гәҗите редакциясе.

**Сл.15** Яңа ел - һәркемнең иң яраткан һәм көтеп алган бәйрәмнәренең берсе. Яңа **ел** бәйрәме кысаларында районда быел да "Иң яхшы яңа **ел** бизәлешенә" традицион конкурсы игълан ителде. Әлеге конкурс бәйрәм көннәрендә бәйрәм күтәренкелеге тудыруны, яңа ел бизәлешенә иҗади якын килүне, яхшыртуны күздә тота. Безнең мәктәп "Иң әкияти бизәлеш" номинациясендә бүләкләнде.

**Сл.16** Мәктәптә тәрбия эшенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе-һөнәри тәрбия. Октябрь аенда Теләче районында «Эшмәкәрлек дәресләре»проекты старт алды. Беренче этапта район эшмәкәрләре өлкән сыйныф укучылары белән очраштылар. Икенче этабында укучылар Теләче Промпарк мәйданчыгы предприятиеләр эшчәнлеге белән таныштылар.

Проектның өченче этабы «WorldSkills Tyulyachi-Junior 2021» ярышлары.Укучылар 6 номинациядә катнашты: "Тегү" номинациясе призеры, бизнес-проектны уңышлы якладылар.

Башлангыч сыйныф укучысы "Мультифест" республика балалар кинофестивалендә "Су анасы" кыска метражлы уен фильмы белән катнаша.

Безнең укучылар «Мәктәп театрына киң юл!» дип исемләнгән IV театр фестивалендә «Үзенчәлекле репертуар» номинациясендә җиңүче.

**Сл.17** Бишенче ел мәктәп сәламәтлек мәктәбе муниципаль инновацион мәйданчыгы булып тора.

**Сл.18** Шуның кысаларында "Кече олимпия уеннары" , " Нәниләр чаңгы юлы(лыжня - малышня)" район ярышлары үткәрелә. Төрле ярышларда катнашып 80 нән артык урын яуладык. Без районның ГТО , армспорт командалары составында.

**Сл.19** Тәрбия өлкәсендәге һәрбер эшчәнлек хокук, гражданлык, әхлак, патриотик, физик һәм Россия тәңгәллеген формалаштыру , һөнәри юнәлеш һәм хезмәт тәрбиясе бирү аша оештырыла. Мәктәп буенча район күләмендә учетта торучы укучылар юк.

Укучыларга төпле белем һәм тәрбия бирү, аларны олы тормыш юлына әзерләү безнең һәрберебезнең изге бурычы. Ә моның өчен бары теләк һәм тырышлык, үз өстеңдә эшләү кирәк. Безнең коллектив моңа сәләтле.